ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23 июнь, 2022 ел № 15/9

Шәһәр Советының 2019 елның 24 гыйнварындагы 29/6 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәрендә спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасында Спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 25 сентябрендәге 853 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары белән расланган «Татарстан Республикасында Спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 1 сентябрендәге 768 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2019 елның 24 гыйнварындагы 29/6 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәрендә спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә (Шәһәр Советының 2020 елның 11 августындагы 41/8, 2021 елның 27 декабрендәге 11/7 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 9 пунктта «16 640» санынннан соң түбәндәге эчтәлекле 9.1 пункт өстәргә:

«9.1. Спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләре тарафыннан бер сәгатьлек база окладны (хезмәт хакының база ставкасы) өчен хезмәт күрсәтүләрнең норматив саны:»;

2) 9.1 пунктның 1 таблицасында түбәндәге эчтәлекле 82 пунктча өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «82. | Кыяга таугa менү | 2,2 | 3,3 | 6,3 | 8,3 | 8,3 | 14,3 | 16,7 | 20,0 | 33,3 | 51,9 | 88,9»; |

3) 9.1 пунктның 2 таблицасында түбәндәге эчтәлекле 82 пунктча өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «82. | Кыя тауга менү | 4 | 6 | 9 | 12 | 12 | 18 | 18 | 18 | 24 | 28 | 32»; |

4) 9.1 пунктның 3 таблицасында түбәндәге эчтәлекле 82 пунктча өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «82. | Кыя тауга менү | 10 | 10 | 8 | 8 | 8 | 7 | 6 | 5 | 4 | 3 | 2»; |

5) 90 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«90. Башкарма комитет спорт резервын әзерләүче оешма җитәкчесенә тренерларның югары квалификацияле спортчылар әзерләгәне һәм спортчылар, спортчы-инструкторларның ярышларда алган нәтиҗәләре өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр билгели.

Спорт резервын әзерләүче оешма җитәкчесе укыту-тренировка процессын оештыру һәм тәрбия эшләре мәсьәләләре буенча җитәкче урынбасарларына тренерларның югары квалификацияле спортчылар әзерләгәне һәм спортчылар, спортчы-инструкторларның ярышларда алган нәтиҗәләре өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр билгели ала.

Спорт резервын әзерләүче оешма җитәкчесенә, укыту-тренировка процессын һәм тәрбия эшен оештыру мәсьәләләре буенча җитәкче урынбасарларына тренерларның югары квалификацияле спортчылар әзерләгәне һәм спортчылар, спортчы-инструкторларның ярышларда алган нәтиҗәләре өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне башкару өчен чираттагы финанс елына чыгымнар күләме түбәндәге формула белән хисаплана:

$$V_{VKS_{ruk_i}} = \frac{\sum V_{VKS_{ruk_{svod}}}}{\sum V_{VKS_{tren\text{-}pred_{svod}}}} \times \sum V_{VKS_{tren\text{-}pred_i}},$$

монда:

$V_{VKS_{ruk_i}}$ - спорт резервын әзерләүче оешма җитәкчесенә, укыту-тренировка процессын һәм тәрбия эшен оештыру мәсьәләләре буенча җитәкче урынбасарларына тренерларның югары квалификацияле спортчылар әзерләгәне һәм спортчылар, спортчы-инструкторларның ярышларда алган нәтиҗәләре өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне башкару өчен чираттагы финанс елына чыгымнар күләме;

$V_{VKS_{ruk_{svod}}}$ - спорт резервын әзерләүче оешма җитәкчесенә, оештыру һәм тәрбия эшләре мәсьәләләре буенча җитәкче урынбасарларына агымдагы финанс елыннан алдагы елда тренерларның югары квалификацияле спортчылар

әзерләгәне һәм  спортчылар, спортчы-инструкторларның ярышларда алган нәтиҗәләре өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне башкару өчен чыгымнарның гомуми күләме;

$V_{VKS_{tren\text{-}pred_{svod}}}$ - спорт резервын әзерләүче оешманың тренер-укытучыларына агымдагы финанс елыннан алдагы югары квалификацияле спортчылар әзерләгән һәм  спортчылар, спортчы-инструкторларның ярышларда алган нәтиҗәләре өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне башкару өчен чыгымнарның гомуми күләме;

$V_{VKS_{tren\text{-}pred_{i}}}$ - спорт резервын әзерләүче оешманың тренер-укытучыларына агымдагы финанс елыннан алдагы елда югары квалификацияле спортчылар әзерләгән һәм  спортчылар һәм спортчы-инструкторларның ярышларда алган нәтиҗәләре өчен кызыксындыру характерындагы  айлык түләүләрне башкару өчен чыгымнар күләме.

Спорт резервын әзерләүче оешма җитәкчесенә, укыту-тренировка процессын һәм тәрбия эшен оештыру мәсьәләләре буенча җитәкче урынбасарларына тренерларның югары квалификацияле спортчылар әзерләгәне һәм  спортчылар, спортчы-инструкторларның ярышларда алган нәтиҗәләре өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне башкару өчен средстволар оешма җитәкчесен стимуллаштыруга 50 процент һәм укыту-тренировка процессын һәм тәрбия эшен оештыру мәсьәләләре буенча җитәкче урынбасарларын стимуллаштыруга 50 процент күләмендә бүленә.

Спорт резервын әзерләүче оешма җитәкчесенә, укыту-тренировка процессын һәм тәрбия эшен оештыру мәсьәләләре буенча җитәкче урынбасарларына тренерларның югары квалификацияле спортчылар әзерләгәне һәм  спортчылар, спортчы-инструкторларның ярышларда алган нәтиҗәләре өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр ай саен башкарыла.».

2. Әлеге Карар рәсми бастырылганнан көннән гамәлгә керә һәм 2020 елның 1 сентябреннән соң хасил булган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме | Н.Г. Мәһдиев